**КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**
ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА
БАГЛАНЫШЛАР ИНСТИТУТЫ
***Татар тел белеме кафедрасы***

**Д.Х. ХӨСНЕТДИНОВ, Р.К. СӘГЪДИЕВА, Р.Х. МИРЗАҺИТОВ**

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНДА УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА ҮТКӘРҮ БУЕНЧА МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

Казан – 2019

**УДК 8-81**
**ББК 6/8**

*КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Гыйльми советының уку-укыту методик комиссиясе карары нигезендә бастырыла*
*(5 нче номерлы беркетмә, 15 февраль, 2019 ел)*

**Фәнни мөхәррире**:
педагогика фәннәре докторы, профессор **Ф.Ф. Харисов**
**Рецензентлар:**
филология фәннәре кандидаты, доцент **А.Ф. Юсупов**
педагогика фәннәре кандидаты, доцент **М.М. Шакурова**

**Хөснетдинов Д.Х.,**
**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар теленнән олимпиада үткәрү буенча методик күрсәтмәләр** / Д.Х. Хөснетдинов, Р.К. Сәгъдиева, Р.Х. Мирзаһитов. – Казан, 2019. – 56 б.

Кулланма югары уку йортының татар филологиясе бүлегендә белем алучы магистрларга юнәлдерелгән. Методик материаллар татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучылары өчен татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиадаларны үткәрү буенча методик күрсәтмәләрне, олимпиада биремнәренең төзелешенә һәм эчтәлегенә хас таләпләрне, катнашучыларның белемен бәяләү үзенчәлекләрен үз эченә ала. Ахырдан үрнәк биремнәр урын алды.

© Казан федераль университеты, 2019
© Хөснетдинов Д.Х., Сәгъдиева Р.К., Мирзаһитов Р.Х., 2019

## 1. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданың эчтәлегенә күзәтү, тәкъдим ителә торган биремнәрне тасвирлау

### 1.1. Татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданың максаты

Мәктәптә уздырыла торган олимпиада – укучыларны теге яки бу предметны өйрәнүгә кызыксыну тудыру, укучылар һәм укытучыларның белем дәрәҗәсе өчен җаваплылык хисен барлыкка китерү, бер-берең белән ярышу, көч сынашу мохитен тудыру, гадел көндәшлек булдыру, укучыларның интеллектуаль потенциалын тормышка ашыру, өстәмә белем бирүнең барлык эш төрләре буенча нәтиҗә ясау максатыннан оештырыла торган мохит.

Олимпиада – теге яки бу предмет буенча класстан тыш массакүләм чаралар арасында иң киң кулланылыштагы төр. Ул укучыларны яңа заман шартларында һәм, иң мөһиме, конкуренция шартларында яшәргә өйрәтергә булыша. Бүгенге көндә укучыларның олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләре мәктәптә, шәһәрдә, республикада белем бирү дәрәҗәсен ачыклый торган бер критерий булып тора, укытучының эшчәнлек дәрәҗәсен бәяләргә ярдәм итә.

Укучыны олимпиадага әзерләү нигезендә системалылык, эзлеклелек ятарга тиеш: мондый төр ярышларга укучыны башлангыч сыйныфлардан ук әзерләү мөһим. Өченче сыйныфта мәктәп күләмендә еллык олимпиадалар уздырып карарга мөмкин. Призлы урыннарга лаек булган укучылар параллель сыйныфта белем алган җиңүче балалар белән үзара көч сынашалар. Жюри һәр катнашучының эшен тикшерә, анализ ясый һәм төрле номинацияләр буенча җиңүчеләрне билгели, мәсәлән, “Татар теленең иң яхшы белгече”, “Иң яхшы филолог” һ.б. Олимпиадада катнашкан укучы үз җиңүләрен, төрле бәйгеләрдә катнашкан мәгълүматларны бер папкага туплап барса, алга таба кулайрак була.

Татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләм олимпиада 4-11 сыйныфлар арасында уздырыла. **<u>Мәктәптә уза торган</u>** олимпиадада укучы

үз теләге белән катнашырга тиеш. Аның татар теле дәресләрендә алган билгеләре исәпкә алынмый.

Мәктәптә үткәрелә торган олимпиада биремнәрен төзү һәм аны уздыру өчен, укучыларны түбәндәгечә бүлү мәслихәт:

1. 4 сыйныф
2. 5-6 сыйныфлар
3. 7-8 сыйныфлар
4. 9 сыйныф
5. 10-11 сыйныфлар

Шуны истә тотарга кирәк: нәтиҗәләр һәр сыйныфка аерым чыгарыла.

Мәктәп олимпиадасында җиңгән һәм призлы урыннарга лаек булган укучылар олимпиаданың башка этапларында катнашу өчен туплана торган командага сайлап алу турында катнашалар. Һәр ел саен муниципаль дәрәҗәдә үткәрелә торган олимпиадага бер команда туплана. Әлеге команда белән эшләү, аларны олипиадага әзерләү өчен, аерым бер мәктәп укытучысы яисә югары уку йортында эшли торган галим чакырылырга мөмкин.

Әлеге эш системасы олимпиадага уку елы дәвамында эзлекле әзерләнергә һәм көчле команда тупларга ярдәм итә. Команда җитәкчесе, укучыларны бергә җыеп, аларның белем системасын билгеле бер тәртипкә китерергә тиеш.

Муниципаль күләмдә үткәрелә торган олимпиада нәтиҗәләре Мәгариф һәм фән министрлыгында бергә туплана, нәтиҗә ясала, һәм иң югары балл туплаган укучылар республика күләмендә уздырыла торган олимпиадага чакырыла. Шул сәбәпле һәр муниципаль оешмадан һәр сыйныфтан берәр җиңүче түгел, ә гомум баллар чыгарылганнан соң җиңүче дип табылган 4-11 сыйныф укучылары чакырыла. Нәтиҗәдә, аерым муниципаль оешмадан ун укучы көч сынашырга, ә икенчесеннән бер укучы да катнашмаска мөмкин. Республика күләмендә уздырыла торган олимпиадада, чыннан да, Татарстан республикасындагы иң көчле балалар үзара көч сынаша.

Татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиаданың максатлары түбәндәгеләр:

- укучыларның татар теле белән кызыксынуларына этәргеч бирү;
- укучыларның татар теле дәресләрендә алган белемнәрен тирәнәйтү;
- татар тел белеме белән кызыксынучы укучыларны табу;
- укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- укучыларга үз сәләтләре һәм белемнәре белән бәйле булган югары уку йортларын табарга ярдәм итү.

**Муниципаль һәм республика күләмендә** уздырыла торган олимпиадада 4-11 сыйныф укучылары катнашырга хокуклы. Һәр сыйныф өчен биремнәр аерым төзелергә тиеш.

Укучыларны муниципаль һәм республика олипиадасына әзерләү өчен, аерым уку-укыту программасын төзү мөһим. Шул ук вакытта һәр сыйныф һәм һәр укучы өчен индивидуаль белем бирү юнәлешен булдыру кирәк. Укучыларны муниципаль һәм республика күләм олимпиадаларга әзерләү максатыннан, югары уку йорты галимнәрен чакыру, әлеге эшкә аларны җәлеп итү уңай нәтиҗәләр бирә.

Берничә дәресне психологлар үткәргән очракта, бу укучыларга олимпиада вакытында була торган стресс халәтеннән котылырга ярдәм итәчәк.

## 1.2. Биремнәрне төзүгә гомум таләпләр

Биремнәр төгәл, грамоталы, укучыларга аңлаешлы итеп һәм мәктәп программасында үтелә торган терминнардан гына төзелергә тиеш. Аларны телдәге бәхәсле, ике төрле фикер йөртергә урын калдыра торган сораулардан төзү катгый тыела.

Биремнәрдә җавап формасы күрсәтелергә мөмкин (астына сызарга, дөрес җавапны күрсәтергә, кушымчаларны билгеләргә һ.б. ), ә кайчак аның күләме дә искәртелә (мәсәлән, җавап язу өчен тел берәмлекләренең саны күрсәтелә). Өстәмә сорауларга җавап бирү аерым бәяләнгән очракта, биремдә бу хакта

укучыга күренеп торырлык итеп искәртелергә тиеш. Болар барысы да катнашучының белемен гадел бәяләү өчен мөһим.

Олимпиаданың күп кенә биремнәре тулы җавап язуны таләп итә, чөнки шул очракта гына укучының язу культурасын, үз фикерен эзлекле һәм аңлаешлы итеп әйтә белүе, грамоталылыгы күренә. Тулы җаваплар теге яки бу тел берәмлегенең эчтәлеген генә ачып бирми, ә, бәлки, аның грамматик, стилистик белемен дә, этимологияне, тарихи-мәдәни тел кыйммәтләрен белүе дә аңлашыла, җавапны бер тәмамланган бөтен итеп оештыра алуы бәяләнә.

Мондый төр биремнәр “исбатлагыз”, “аңлатып бирегез”, “җавабыгызны дәлилләгез” дигән формада бирелергә тиеш. Укучы бу очракта, үзенең фикерен дәлилләү өчен, грамматик белемен генә түгел, ә күзәтүләрен дә эшкә җигәргә тиеш.

## 1.3. Бирем төрләре

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен шартлы рәвештә ике төргә бүләргә мөмкин: лингвистик тестлар һәм лингвистик мәсьәләләр.

***1. Лингвистик тестлар***

Мондый төр биремнәр укучыларның мәктәп программасы кысаларында өйрәнелә торган тел берәмлекләрен анализлау белән бәйле белемнәрен тикшерүне максат итеп куя. Тестлар, гадәттә, һәр тел тармагына бирелә, мәсәлән, фонетика, лексикология, сүз ясалышы, морфология, синтаксис. Тестлар ачык яисә ябык була ала. Анда һәм теоретик, һәм практик сораулар урын алырга мөмкин. Ләкин тестның сораулары да, тәкъдим ителгән җавап вариантлары да бер үк төрле булырга тиеш. Гадәттә, бер тестка 4 төрле җавап вариантын бирү уңышлы. Ләкин 4 нче сыйныф укучылары өчен 3 төрле җавап вариантын бирү дә җитә.

Тестларны төзү оештыручылардан төгәллек таләп итә. Әлеге төр биремнәрдә җавапны ике төрле вариант итеп билгели алырлык сораулар булырга тиеш түгел.

***2. Лингвистик мәсьәләләр***

Лингвистик мәсьәләләр укучының татар теленнән туплаган белемнәрен; фонетик, лексик, сүз ясалышы, морфологик һәи синтаксик анализ күнекмәләрен; телне сиземләүен; күзәтү, тасвирлау, чагыштыру, системалаштыру, гомумиләштерүгә бәйле тикшеренү алымнарын куллана белүен бәяләүне күздә тотып төзелә.

Бу биремдә укучы өчен аерым текст тәкъдим ителергә мөмкин, һәм укучы үзенең мәктәптә уку дәверендә алган теоретик һәм практик күнекмәләрен ачып бирергә тиеш.

Шуны да онытмаска кирәк: олимпиада укучының белемен генә тикшереп калмый, ә аның тел белән кызыксынуын да арттыра. Катнашучы әлеге олимпиададан үзенә ниндидер яңалык та алып китә. Шуңа күрә укучы өчен тарихи коментарийлар, әдәби әсәрдән цитаталар яисә фәнни хезмәтләр белән таныштыру да урынлы булыр.

Олимпиада биремнәрендә укучыны теоретик сораулар белән ялыктыру урынсыз. Укучының теге яки бу теоретик мәгълүматны тормышта, сөйләмдә ничек куллана белүен ачыклау мөһим. Укучыга билгеле бер фикер яисә тема белән бәйле иҗади эш тә тәкъдим ителергә мөмкин.

**Биремнәргә таләпләр:**

- тәкъдим ителгән сораулар оригиналь, башка методик кулланмаларда һәм Интернетта булмаска тиеш;
- олимпиада биремнәрен төзегәндә, әлеге методик киңәшләргә таянырга кирәк;
- сораулар ирекле тәртиптә төзелә, ләкин, гадәттә, аларны җиңелдән авырга таба бару ысулы белән төзү уңышлы;
- сораулар бер генә җавап табуны күздә тотылып төзелергә тиеш. Әгәр берничә җавапны табарга кирәк булса, бу хакта, һичшиксез, искәртелә.

- муниципаль һәм региональ методик оешма үз төбәгенең этномәдәнияте, диалекталь үзенчәлекләре, җирле сөйләше һәм әдәбияты белән бәйле 2-3 сорау бирергә хокуклы.

Татар теленнән Республика олимпиадасы 3 этаптан гыйбарәт, шуңа күрә биремнәрне эшләгәндә, барлык комиссия биремнәрне бер төрле системада төзесә, эшнең нәтиҗәсе һәм укучының әзерлеге күпкә отышлырак була. Әлеге тәртипкә укучыны башлангыч сыйныфта укыганда ук әзерли башларга кирәк.

Олипиада эшләрен бәяләгәндә, укучының мәктәп программасын белүе генә түгел, ә лингвистик эрудициясе, телне сиземләве, тоемлавы, логик фикерли белүе дә исәпкә алынырга тиеш. Орфографик, пунктуацион, стилистик нормаларның сакланышын да аерым бәяләү мөһим.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен төзегәндә, хаталарның бердәм системасын исәпкә алу нормалары булдырыла. Балларны кую системасының нигезен төзеп кую да таләп ителә.

### 1.4. Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада үткәрү өчен төзелгән биремнәрне тасвирлау

Биремнәрне төзегәндә, олимпиадада катнашучыларның түбәндәге белемнәрен чагылдыруларын исәптә тотарга кирәк:

- татар әдәби теленең орфоэпик нормаларына ия булуларын (басым, арткы һәм алгы рәт сузыкларны аеру, татар теленә хас тартыкларны һәм сузыкларны әйтү һ.б.);
- татар теленең алфавитын һәм орфографик кагыйдәләрен белүләре;
- хәзерге татар әдәби теленең семантик төзелешен, лексик берәмлекләрнең килеп чыгышын һәм мәгънәсен аңлаулары;
- татар теленең фразеологик берәмлекләрен сөйләмдә дөрес куллана алулары;
- тел берәмлекләрен сүз төзелеше ягыннан таркату күнекмәләре;
- татар теленең морфологик төзелешен һәм сүзгә морфологик анализ ясый белүләре;

- татар теленең синтаксик төзелешен һәм җөмләгә синтаксик анализ ясый белүләре;
- татар теле тарихыннан хәбәрдарлыгы;
- коммуникатив белем һәм күнекмәләргә ия булулары.

**Биремнәрне темаларга бүлү түбәндәгечә тормышка ашырылырга мөмкин:**

1) фонетика һәм орфоэпия (хәреф һәм авазларның тәңгәллек үзенчәлекләрен ачыклау, орфоэпик нормаларны куллану, кагыйдәдән искәрмәләрне урынлы файдалану һ.б.);

2) графика һәм орфография (орфографик хаталарны табу; сүзләрнең дөрес язылышын күрсәтү);

3) лексикология һәм фразеология (сүзләрнең лексик мәгънәсен аера белү, фразеологик берәмлекләрнең мәгънәсенә төшенү);

4) лексикография (лексикографик материал белән эшли белү, сүзлекләрнең төзелешен аңлау);

5) грамматика (сүзләрнең грамматик төзелешен тану; сүзгә дөрес морфологик анализ ясау, җөмләдәге синтаксик ролен билгеләү);

6) функциональ стилистика (тел сурәтләү чараларын уңышлы файдалана белү, аларның җөмләдә һәм текстта кулланылыш үзенчәлекләрен тасвирлау);

7) тел тарихы, диалектология (сүзнең килеп чыгышын, мәгънәсен, яңа һәм искергән сүзләрнең кулланылышын аңлау, диалектизмнарның матур әдәбиятта кулланылыш үзенчәлекләрен тоемлау).

Олимпиада татар теленнән сәләтле балаларны сайлап алу, барлау чарасы булганга, тәкъдим ителгән биремнәр телнең төрле берәмлекләре, аларның үзенчәлекләре турында уйландыруны максат итеп куярга тиеш. Укучылар мәктәп программасы кысаларында тупланган белемнәрен татар телен сурәтләгәндә, тирәнтен өйрәнүне таләп итә торган мәгълүматларны табарга, “телне сиземләү” алымын куллана белергә тиешләр. Укучылар, күзәтү алымы

ярдәмендә тел берәмлекләренә мөстәкыйль анализ ясап, билгеле бер нәтиҗә ясый алуларын күрсәтергә мәҗбүр. Мондый төр биремнәр югары уку йорты дәреслекләреннән алына алмый. Укучы татар әдәби телен һәм үз җирлегендә кулланыла торган диалекталь берәмлекләрнең функциясен, үз тәҗрибәсенә таянып ачыкларга, кулланылыш үзенчәлекләрен тасвирлап бирергә тиеш. Моннан тыш, әлеге төр биремнәрне 4-7 сыйныфларга бирмәскә киңәш ителә.

Төрле сыйныф укучылары өчен олимпиада биремнәрен төзегәндә, аларның кайсы темаларны үткәнлеген, өйрәнгәнлеген истә тотарга кирәк.

## 2. Тәкъдим ителгән биремнәрнең эчтәлегенә бәйле материаль-техник яктан тәэмин ителеш исемлеге

Татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдәге олимпиада уздыру өчен, мәктәпнең сыйныф бүлмәләре таләп ителә. Һәр катнашучы сыйныф бүлмәсендә аерым парта артында утырырга тиеш. Республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада исә аерым билгеләнгән һәм катнашучыларга алдан ук искәртелеп куелган зур бинада уздырыла. Монда катнашучылар өчен йокы һәм аш бүлмәләре булу мәҗбүри. Әлеге олимпиада да бер өстәл артында төрле сыйныф укучылары утыртыла, ләкин алар бер үк муниципаль оешмадан булмаулары шарт итеп куела.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олипиадада җитәрлек дәрәҗәдәге биремнәр саны, аклама һәм каралама өчен кәгазь битләре, авторучкалар, кыстыргычлар һәм степлерлар кирәк. Олимпиадада катнашучыларның рейтингын төзү өчен, MS Excel программасы булган компьютер (ноутбук) куллану киңәш ителә. Материалның тиражын арттыру өчен ксерокс яисә принтер таләп ителә. Олимпиада уздырыла торган бина эчендә барлык кирәкле җиһазлары булган медицина пункты белән дежур табиб булуы шарт. Ул олимпиаданың башлану вакытыннан алып тәмамлануына кадәр бинада булырга мәҗбүр.

Муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданы уздырганда, нәтиҗәлелекне арттыру максатыннан, укучыларның эшләрен сканировать итеп алу киңәш ителә. Шуның белән бәйле оештыру комитеты кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителергә тиеш.

## 3. Татарстан республикасында уздырыла торган татар теленнән мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданың үзенчәлекләрен тасвирлау:

а) олимпиаданы оештыручы комитет һәм жюри;

ә) олимпиаданы уздыру тәртибе һәм формасы;

б) нәтиҗәләр чыгару;

в) өстәмә бәйгеләр һәм бәйгедән тыш чаралар.

а) олимпиаданы оештыручы комитет һәм жюри.

4-11 сыйныфлар өчен татар теленнән **мәктәп** күләмендә үткәрелә торган олимпиада ел саен 1 нче ноябрьгә кадәр уздырыла.

Олипиада уздыру урыны һәм вакыты белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган җирле үзидарә оешмалары тарафынннан билгеләнә. Оештыру комитеты район, шәһәр, мәктәп администрациясе, гуманитар бүлек укытучылары әгъзаларыннан оешырга мөмкин. Жюри әгъзалары татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм әлеге белем бирү оешмалары администрацияләреннән туплана.

Мәктәп дәрәҗәсендә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм муниципаль предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән, татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла.

Татар теленнән мәктәп күләмендә уздырыла торган олимпиаданың оештыру-техник тәэмин ителеше оештыру комитеты карамагында.

Жюри олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен билгели.

**Муниципаль** күләмдәге олимпиада ел саен 25 нче декабрьгә кадәр уздырыла.

Муниципаль дәрәҗәдәге олимпиаданы уздыруның төгәл вакыты РФ субъектларындагы белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган дәүләт оешмалары хакимияте тарафыннан билгеләнә. Муниципаль дәрәҗәдәге олимпиаданы уздыруның төгәл урынын белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган җирле үзидарә оешмасы билгели.

Әлеге этапның төп максаты – республика күләмендәге олимпиадада катнашыр өчен иң сәләтле һәм көчле балаларны ачыклау.

Бу олимпиаданы уздыру өчен оештыру комитеты, предмет-методик комиссия һәм муниципаль дәрәҗәдәге олимпиада жюрие туплана. Оештыру комитетына шәһәрнең, районның, мәктәп администрациясенең метод хезмәткәрләре, гуманитар циклдагы предмет укытучылары керә ала. Предмет-методик комиссиягә һәм жюрига мәктәп укытучылары белән беррәттән танылган телче-галимнәр һәм югары уку йортының татар теле кафедрасы методистлары керергә мөмкин. Муниципаль дәрәҗәдә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм региональ предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла.

Жюри олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен һәм призерларын билгели.

**Республика** күләмендәге олимпиада ел саен январь ахыры – февраль башында уздырыла.

Республика күләмендәге олимпиаданы уздыруның төгәл вакыты һәм урыны РФ субъектларындагы белем бирү өлкәсе белән идарә итә торган дәүләт оешмалары хакимияте тарафыннан билгеләнә.

Әлеге этапның төп максаты – Татарстан республикасында белем ала торган иң сәләтле һәм көчле балаларны барлау.

Бу олимпиаданы уздыру өчен оештыру комитеты, предмет-методик комиссия һәм республика күләмендәге олимпиада жюрие туплана. Оештыру комитетына республиканың метод хезмәткәрләре, предмет укытучылары керә ала. Предмет-методик комиссиягә һәм жюрига танылган телче-галимнәр һәм югары уку йортының татар теле кафедрасы методистлары җәлеп ителә. Республика дәрәҗәсендә уздырыла торган олимпиада шул этапка туры килә торган һәм республика предмет-методик комиссиясе тарафыннан төзелгән һәм татар теленнән Үзәк предмет-методик комиссиясе тәкъдим иткән методик киңәшләрне исәптә тотып эшләнгән биремнәр буенча уздырыла.

Жюри олимпиада биремнәренең эшләнешен бәяли, эшләнгән олимпиада биремнәренә анализ ясый, укучы теләге белән аңа үзе эшләгән эшнең бәяләнешен күрсәтә, видеофиксация кулланып, укучыга аппеляция уздыра, бүлеп бирелгән квотага һәм нәтиҗәләргә бәйле әлеге этапның җиңүчеләрен һәм призерларын  билгели.

<u>ә) олимпиаданы уздыру тәртибе һәм формасы.</u>

4-11 сыйныф укучылары өчен татар теленнән **<u>мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә</u>** үткәрелә торган олимпиада төгәл сорауларга яисә билгеле бер лингвистик биремнәргә җавап бирү формасында язмача бер турда уздырыла.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиаданы үткәрү өчен, берничә сыйныф бүлмәсен бүлеп бирү киңәш ителә. Һәр укучы аерым бер партада утырырга тиеш (республика күләмендәге олимпиадада төрле сыйныф һәм төрле муниципаль оешмалардан килгән укучыларга бер партада артында

утырырга рөхсәт ителергә мөмкин), ул эш биремнәре һәм канцелярия әсбаплары (кәгазь, ручка) белән тәэмин ителә.

Олимпиаданы җирле вакыт белән сәгать 9.00 башлау киңәш ителә.

**Мәктәп** һәм **муниципаль** дәрәҗәсендә үткәрелә торган олимпиада биремнәрен башкарыр өчен киңәш ителә торган вакыт:

4-6 сыйныфлар өчен – 60 минут, 7-8 сыйныфлар өчен 120 минут, 9-11 сыйныфлар өчен – 180 минут.

**Республика** күләмендә уздырыла торган олимпиада биремнәрен башкарыр өчен барлык сыйныфларга да 240 минут вакыт бирелә.

Олимпиада башланыр алдыннан, оештыручылар катнашучылар өчен инструктаж, ягъни күрсәтмәләр уздыралар: биремнәрне үтәр өчен күпме вакыт бирелгәнлеге искәртелә, чыгарылган баллар белән риза булмаган очракта аппеляциягә бирү тәртибе белән таныштырыла, олипиадада үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеге аңлатыла, шулай ук интеллектуаль ярыш нәтиҗәләре белән кайчан һәм кайда танышып булачагы хәбәр ителә.

**Олимпиада вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре:**

- биремнәрне үтәү вакытында, катнашучыларның бер-берсе белән аралашырга, бүлмә буйлап йөрергә хокуклары юк. Катнашучы бары тик, дежур укытучы яки вәкил итеп билгеләнгән зат озаткан очракта гына, аудиториядән чыга ала. Бу очракта дежур укытучы эшнең тышкы ягына чыгу вакытын язып куярга тиеш;
- катнашучының аудиториядән олимпиада белән бәйле материалларны (бирем бланкларын, җавап кәгазен, караламаны) алып чыгарга хокукы юк;
- катнашучыга аудиториягә кәгазь, белешмә материаллар, электрон чаралар, диктофоннар, плеерлар, электрон китаплар, фотоаппаратлар, смарт-сәгатьләр һәм башка шундый техник җиһазлар алып керү катгый тыела;
- татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдәге олипиаданы уздыру тәртипләрен һәм таләпләрен бозган очракта, катнашучыны оештыручы

аудиториядән чыгарып җибәрергә хокуклы. Бу очракта әлеге катнашучыны чыгарып җибәрү хакында акт төзелә;

- аудиториядән чыгарылып җибәрелгән катнашучылар әлеге уку елында татар теленнән уздырыла торган олимпиадларда катнашудан мәхрүм ителә.

Татар теленнән мәктәп һәм муниципаль дәрәҗәдә уздырыла торган олимпиаданы оештыру һәм контрольдә тоту өчен, башка предмет укытучыларын җәлеп итү киңәш ителә.

Билгеләнгән вакыт чыгу белән, укучыларның эшләре җыеп алына һәм эшләрне кодлаштыра һәм жюри рәисенә тапшыра торган оештыру комиссиясенә тапшырыла.

Жюри башкарылган олимпиада биремнәрен тикшерә һәм бәяли. Муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиада биремнәрен тикшергәндә, объектив бәяләү максатыннан, бер үк эшне тулаем бер үк жюри әгъзасы карау киңәш ителми. Бер сыйныфта укучы катнашучыларның эшләрен төркемләп тикшерү уңай һәм гадел нәтиҗәләр бирә.

Оештыру комитеты һәр биремгә куелган балларны куша, һәм тулы бер эшнең гомум баллары чыга.

Оештыру комитеты рейтинг төзи, тапшырылган эшләрнең кодларын ача, жюри олимпиаданың җиңүчеләрен һәм призерларын билгели.

Олипиаданың тиешле этабын уздырганнан соң, белем бирү оешмалары белән идарә итә торган җирле үзидарә органнарының официаль сайтларына, Интернет челтәренә барлык сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән биремнәрне элү киңәш ителә. Төгәл биремнәрне күрү, аларны үзлектән эшләп карау катнашучыларның белемнәрен генә арттырмый, ә укучыларның татар теле белән кызыксынуларын да арттыра.

Республика күләмендә уздырылган олимпиадада җиңү яулаган һәм призерлар исемлегенә кергән катнашучыларның эшләре Интернет челтәренә эленергә тиеш. Бу исә, беренчедән, жюри әгъзаларына җаваплылык, төгәллек

таләп итсә, икенчедән, катнашучыларга үз эшләрен гадел бәяләүләре хакында дәлил булып хезмәт итә.

б) нәтиҗәләр чыгару.

Эшләрне тикшереп бетергәннән соң, аларга анализ һәм укучыны нәтиҗәләр белән таныштыру эшләре үткәрелә, шулай ук катнашучыларның апелляциягә биргән эшләре карала. Олимпиадага әзерлек дәрәҗәсен арттыру максатыннан, катнашучыларны нәтиҗәләр белән генә таныштырып калмыйча, алар ясаган хаталарга да күзәтү ясау мөһим.

Биремнәрне анализлауның төп максаты – олимпиадада катнашучыларны һәр биремнең җаваплары белән таныштыру гына түгел, ә шулай ук укучылар ясый торган типик хаталарны аңлату, бәяләү критерийларын күрсәтү. Олимпиадада катнашучылар, биремнәрне анализлау вакытында, үзләренең эшләрен объектив бәяләү белән бәйле тулы мәгълүматларны алырга тиеш. Нәтиҗәдә, апелляциягә бирелә торган эшләрнең саны күпкә кимиячәк.

Олимпиадада катнашучылардан башка дистанцион формада тапшырылган эшләргә анализ ясау киңәш ителми.

Жюри олимпиаданы оештыру комиссиясе белән берлектә катнашучыларның апелляцияләрен карый һәм эшләре белән таныштыруны тормышка ашыра. Апелляция уздыруның түбәндәге тәртибе киңәш ителә:

- апелляция олимпиадада катнашучы үзенең олимпиада эшенең нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта уздырыла;
- апелляция тыныч һәм дустанә мохиттә уздырыла;
- олимпиадада катнашучының апелляциясе катгый рәвештә башкарылган олимпиада биремнәренең нәтиҗәләрен игълан иткән көндә уздырыла;
- апелляция уздыруны сорап, олимпиадада катнашучы язмача гариза яза;

- апелляцияне тикшергән вакытта, гариза язган катнашучы үзе генә була, аның үзе белән шәхесен раслый торган документы булырга тиеш;
- апелляция карары нигезендә түбәндәге карарның берсе кабул ителә:
  - апелляцияне кире кагу һәм куелган балларны үз көчендә калдыру;
  - апелляцияне канәгатьләндерү һәм балларга үзгәрешләр кертү.
- олимпиада биремнәрен бәяләү методикасы һәм критерийлары апелляция предметы була алмый һәм кабат тикшерелергә тиеш түгел;
- апелляция буенча карар күпчелек тавыш белән хәл ителә. Тавышлар тәңгәл килгән очракта, жюри рәисе хәл итә торган тавышка ия;
- апелляция карары соңгы булып санала һәм кабат тикшерелми;
- апелляцияне уздыру турында беркетмә тутырыла, жюри һәм оештыру комитеты әгъзалары аңа имзаларын куялар;
- беркетмәгә һәм хисап документларына үзгәрешләр кертү өчен, апелляцияне уздыру турындагы беркетмә жюри рәисенә тапшырыла;
- апелляция уздыру белән бәйле документлар булып түбәндәгеләр исәпләнә:
  - олимпиадада катнашучыларның апелляция үткәрүләрен сорап язган гаризасы;
  - апелляцияны теркәгән журнал (кәгазь бите);
  - апелляцияләрнең беркетмәләре.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендәге олимпиадага түбәндәгечә нәтиҗәләр ясала: иң югары балл туплаган катнашучылар җиңүче булып санала. Ләкин аларга биремнәр өчен куелган гомум баллның яртысыннан артыгын җыю шарт булып тора.

Призлы урыннарга ия булган катнашучыларның саны квотадан чыгып билгеләнә. Әлеге санны шул этаптагы олимпиада оештыручылары билгели.

Бер үк балл туплаган катнашучылар саны квота саныннан артып киткән очракта, әлеге катнашучыларның язмышын жюри әгъзалары хәл итә.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиаданың җиңүчеләре һәм призерлары оештыручылар тарафыннан раслана.

Мәктәп һәм муниципаль күләмдә үткәрелә торган олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар белән бүләкләнә, алар олимпиадның алдагы этабында катнашу хокукына ия булалар.

Республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар белән бүләкләнә. Алар акчалата премиягә тәкъдим ителә.

в) өстәмә бәйгеләр һәм бәйгедән тыш чаралар.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада кысаларында укучының татар теленнән төрле күнекмәләрен үстерә торган өстәмә бәйгеләр уздырылырга мөмкин. Әлеге төр ярышларда җиңү укучыга олимпиаданың алдагы этапларында катнашырга хокук бирми, олимпиада эшен бәяләүдә дә исәпкә алынмый, ләкин татар телен тагын да ныгытып өйрәнүгә этәргеч булып хезмәт итә ала. Мондый төр чараларга түбәндәгеләрне кертергә мөмкин:

- ораторлар бәйгесе;
- татар теле белгечләре бәйгесе;
- шагыйрьләр турниры;
- рефератлар яклау;
- алдан билгеләнгән тема буенча сочинение яисә эссе бәйгесе;
- рус телендәге текстны татар теленә иң яхшы тәрҗемә итүчеләр бәйгесе һ.б.

Язма эш белән бәйле бәйгеләрне бәяләгәндә, түбәндәге үзенчәлекләрне исәпкә алырга кирәк: фикерне дәлилле белү, логик эзлеклелек, композицион төзеклек, сәнгатьлелек, грамоталылык, чыгыш ясау формасы һәм сыйфаты.

Мәктәп, муниципаль һәм республика күләмендә үткәрелә торган олимпиада кысаларында бәйгедән тыш чаралар да уздырылырга мөмкин: экскурсияләр, китап күргәзмәсе, стенгазеталар белән таныштыру, лингвистик уеннар, сөйләм культурасы белән бәйле дискуссияләр оештыру һ.б.

## 4. Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән олимпиада өчен биремнәр

### Татар мәктәбендә укучы балаларга татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
### 4 нче сыйныф

### I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Татар алфавитындагы хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) 36;

ә) 38;

б) 39;

в) 40.

2. Парсыз яңгырау тартыклар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) [м], [н], [ң], [л], [й], [р], [w];

ә) [ц], [щ], [х], [h], [ □ ];

б) [м], [л], [р];

в) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [з], [җ].

3. Калын сузыклардан торган сүзләр рәтен билгеләгез.

а) икмәк, кишер, Гөлчәчәк;

ә) алъяпкыч, тукыма, коймак;

б) бишбармак, тукран, төлке;

в) елан, егет, чыршы.

4. Хәреф белән аваз саны туры килмәгән сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) карбыз, кавын, тарак;

ә) төньяк, өчпочмак, каләм;

б) белем, көньяк, аю;

в) юрган, елга, яфрак.

5. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең килешен билгеләгез.

***Сүздә** мактанма, **эштә** мактан.* (Мәкаль)

а) иялек килеше;

ә) юнәлеш килеше;

б) чыгыш килеше;

в) урын-вакыт килеше.

6. Җыйнак җөмләне билгеләгез.

а) Сафина Ләйсән – тырыш укучы.

ә) Сары яфраклар җир өстен каплаган.

б) Мансурова Лилия, Айдаров Марат – укучылар.

в) Тәрәзәләргә пәрдә эленгән.

7. Үткән заман хикәя фигыль кулланылган җөмләне билгеләгез.

а) Урамда көчле яңгыр ява.

ә) Бүген Азат әбисенә кунакка барды.

б) Спорт сараенда хоккей ярышы булачак.

в) Тиздән кошлар җылы якларга китәр.

8. Ялгызлык исемнәрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) болыт, үлән, агач;

ә) гөлчәчәк, йолдыз, аккош;

б) Айсылу, Идел, “Салават күпере”;

в) ай, кояш, “Су анасы”.

**II. Теоретик бирем.**

Хәзерге заман хикәя фигыль турында язгыз, бер фигыльне зат-сан белән төрләндерегез.

**III. Иҗади бирем.**

Уңнан да, сулдан да бертөрле укыла торган 10 сүз языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән район олимпиадасы биремнәре.**

**4 нче сыйныф**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Тартык авазларны белдерә торган хәрефләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) 13;

ә) 24;

б) 28;

в) 39.

2. Калын сузык авазлардан гына торган мәкальне билгеләгез.

а) Сөйдергән дә – тел, биздергән дә – тел.

ә) Күп сүзнең кыскасы яхшы.

б) Кеше дуслыкта сынала.

в) Саескан сайраса да сандугач булмас.

3. Хәреф белән аваз саны туры килгән сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) егет, вәгъдә, фигыль;

ә) нефть, сәгать, тәкъдим;

б) ашъяулык, ятьмә, меңъяфрак;

в) мөгаен, спектакль, пульс.

4. Мәсәлләрдә, әкиятләрдә җәнлекләр һәм кошлар ничек язылганлыгы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) баш хәрефтән;

ә) юл хәрефеннән;

б) куштырнаклар эченә алынып;

в) баш хәрефтән һәм куштырнаклар эченә алынып.

5. Татар телендә В хәрефенең язылышы дөрес күрсәтлегән рәтне билгеләгез.

а) сүз башында гына языла;

ә) иҗек башында гына языла;

б) сүз һәм иҗек башында языла;

в) сүз һәм иҗек ахырында языла.

6. Башка телләрдән кергән сүзләрнең атамасы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) яңа сүзләр;

ә) алынма сүзләр;

б) искергән сүзләр;

в) синонимнар.

7. Ясалма сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) кулъяулык, көрәк, ата-ана;

ә) агачлык, бозгыч, итәк;

б) бәрәңге, карбыз, тавык;

в) аккош, урман, аш-су.

8. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Татлы тел **еланны** да өненнән чыгарыр.* (Мәкаль)

а) баш килеш;

ә) иялек килеше;

б) төшем килеше;

в) чыгыш килеше.

9. Җөмләдәге фигыльнең заманы һәм зат-сан кушымчалары дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Татлы тел тимер капканы да ачар.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман, III зат берлек санда;

ә) үткән заман, III зат күплек санда;

б) киләчәк заман, II зат берлек санда;

в) киләчәк заман, III зат берлек санда.

10. Җөмләдәге калын хәрефләр белән фигыльнең үзенчәлекләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Исем кешене **бизәми**, кеше исемне бизи.* (Мәкаль)

а) хәзерге заман хикәя фигыль, барлыкта, III зат берлек санда;

ә) хәзерге заман хикәя фигыль, юклыкта, III зат берлек санда;

б) киләчәк заман хикәя фигыль, юклыкта, III зат берлек санда;

в) хәзерге заман хикәя фигыль, юклыкта, II зат берлек санда;

## II. Башыгызны эшләтегез.

Сузык авазга башланган һәм сузык авазга тәмамланган сүзләрдән генә торган “Ял көне” дип аталган текст төзеп языгыз. Барлыгы 10 җөмлә һәм алар җәенке булсын.

## III.Теоретик бирем.

Тамыр һәм ясалма сүзләр турында белгәннәрегезне языгыз.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. ***Балыкчылар*** сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз.
2. Аны сүз төзелеше ягыннан тикшерегез.
3. Балыкчы турында 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз.

# Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының йомгаклау этабы биремнәре.

## 4 нче сыйныф

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Сузык авазларны белдерә торган хәрефләрнең барысы да кулланылган рәтне билгеләгез.

а) а, ә, е, и, о, ө, у, ү, ы;

ә) а, ә, е, и, о, ө, у, ү, ы, ю, я;

б) а, ә, е, ё, и, о, ө, у, ү, ы, э, ю, я;

в) а, ә, е, и, о, ө, у, ү, ы, э, ю, я.

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган җөмләне билгеләгез.

а) *Сөяк бирми – эт иярми.* (Мөсәгыйть Хәбибуллин)

ә) *Китаплар – кешелекнең хәтере.* (Фәнис Яруллин)

б) *Акыллы кеше картайгач та матур кала.* (Шәүкәт Галиев)

в) *Акыллы кеше белән сөйләшү җан рәхәте!* (Мөхәммәт Мәһдиев)

3. Парсыз яңгырау тартыкларның барысы да кулланылган рәтне билгеләгез.

а) [м], [н], [ң], [л], [р], [w], [й];

ә) [б], [в], [г], [гъ], [д], [ж], [з], [җ];

б) [п], [ф], [к], [къ], [т], [ш], [с], [ч];

в) [ц], [щ], [х], [h], [ □ ].

4. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең татар әдәби телендәге варианты дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Тел җәрәхәте кылыч җәрәхәтеннән ачырактыр* ***вә*** *яманрактыр.* (Каюм Насыйри)

а) ләкин;

ә) һәм;

б) ә;

в) я.

5. Ясалма нигезле сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) шатлан, сөен, куан, кайгыр;

ә) шатлану, сөенү, куану, кайгыру;

б) шатлык, бәхет, сөенеч, кайгы;

в) шатлык, сөенеч, куаныч, кайгыру.

6. Кушылып языла торган сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) чәч(тараш), аш(су), мал(туар), бака(яфрагы);

ә) биш(бармак), ун(ике), юл(барыс), каз(аяк);

б) кара(бөрлегән), җиләк(җимеш), нокталы(өтер), бала(чага);

в) каз(үрдәк), яше(карты), уен(көлке), биш(алты).

7. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез.

*Кырда **юлларны** буран күмгән: чистарткыч машина әкрен генә юл ярып бара.* (Шәүкәт Галиев)

а) баш килеш;

ә) иялек килеше;

б) юнәлеш килеше;

в) төшем килеше.

8. Кушымчаларының яңгырау һәм саңгырау вариантлары булган килешләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) баш килеш, иялек килеше, төшем килеше;

ә) юнәлеш килеше, чыгыш килеше, урын-вакыт килеше;

б) юнәлеш килеше, чыгыш килеше, төшем килеше;

в) баш килеше, чыгыш килеше, урын-вакыт килеше.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сыйфатның дәрәҗәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Кеше йокысыннан кояшлы иртәләрне, **алсу** таңнарны сагынып уяна.* (Фәнис Яруллин)

а) гади дәрәҗәдә;

ә) чагыштыру дәрәҗәсендә;

б) артыклык дәрәҗәсендә;

в) кимлек дәрәҗәсендә.

10. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән фигыльнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Надан сүзлек **карамый**, галим аны гомер буе укый.* (Шәүкәт Галиев)

а) үткән заман хикәя фигыль, 3 зат берлек санда, юклыкта;

ә) хәзерге заман хикәя фигыль, 3 зат берлек санда, юклыкта;

б) киләчәк заман хикәя фигыль, 3 зат берлек санда, юклыкта;

в) боерык фигыль, 3 зат берлек санда, юклыкта.

11. Җәенке җөмләне билгеләгез.

а) *Көзге урман матур.*

ә) *Кура җиләге кызарган.*

б) *Шомырт каралган.*

в) *Җиләк-җимеш, чикләвек өлгергән.*

12. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Укыган угыл – атадан олы.* (Хәсән Сарьян)

а) *укыган угыл*;

ә) *олы*;

б) *угыл*;

в) *атадан*.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Түбәндә бирелгән төшенчәләргә 5 әр мисал языгыз.

Ил:

Дәүләт:

Шәһәр:

Авыл:

Тау:

Елга:

Күл:

## III.Теоретик бирем.

Тартык авазлар турында белгәннәрегезне языгыз.

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. ***Альяпкыч*** сүзенә аваз-хәреф анализы ясагыз.

2. Аны сүз төзелеше ягыннан тикшерегез.

3. ***Альяпкыч*** турында 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз.

## Татар мәктәбендә укучы балаларга
## татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр
## 8 нче сыйныф

### I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге сүз басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Кешеләр киләләр дә китәләр, ә ул үзенең язмышы белән тагын ялгыз кала.* (Ф.Яруллин)

а) 2;

ә) 3;

б) 4;

в) 1.

2. Тартыклар ассимиляциясенең яңгыраулыкта охшашлануы күзәтелгән сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Ипи авырлыгыннан киштәләр сыгылган, әйтерсең бөтен дөнья байлыгы монда җыелган.* (Ф.Яруллин)

а) авырлыгыннан, байлыгы;

ә) сыгылган;

б) сыгылган, монда, җыелган;

в) авырлыгыннан, сыгылган, байлыгы, монда, җыелган.

3. Тарихи сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) куцат, айбагар, ихата, әпәй;

ә) анализ, вакланма, формула, интервал;

б) мәктүп, инсан, берлән, өмит;

в) кистән, шишәк, көбә, пищаль.

4. Җөмләдәге алмашлыкка дөрес морфологик анализ ясалган рәтне билгеләгез.

*Үзенең йомшаклыгын таныган кеше көчле кешегә әверелә.* (О.Бальзак)

а) зат алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә;

ә) билгеләү алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә;

б) күрсәтү алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә;

в) тартым алмашлыгы, берлек санда, иялек килешендә.

5. Җөмләдәге сан төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Песнәкләрнең уңнан тугызы суыктан түгел, ачлыктан үлә.* (Календарьдан)

а) микъдар;

ә) тәртип;

б) чама;

в) бүлем.

6. Дүртюллыктагы хәл фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Өйләрдә ут сүнеп,*
*Урамнар тын калгач,*
*Кыш килгән авылга,*
*Кешеләр йоклагач.* (Г.Сәгыйров)

а) сүнеп;

ә) калгач, йоклагач;

б) калгач, килгән, йоклагач;

в) сүнеп, калгач, йоклагач.

7. Калын хәрефләр белән бирелгән хәбәрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Эш беткәч кенә **тантана ит**.* (И.Гёте)

а) тезмә исем хәбәр;

ә) кушма исем хәбәр;

б) тезмә фигыль хәбәр;

в) кушма фигыль хәбәр.

8. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Кошлар оя **ясаучыларга** рәхмәт укыдылар.* (А.Алиш)

а) ия;

ә) тәмамлык;

б) аныклагыч;

в) урын хәле.

## II. Теоретик бирем.

Тиңдәш кисәкләр янындагы тыныш билгеләрен аңлатып языгыз.

## III. Гамәли һәм иҗади бирем.

1. Табышмакны укыгыз, җавабын языгыз.

*Өр-яңа савыт тишелеп беткән,*

*Тишекләреннән ак яңгыр үткән.* (Табышмак)

2. *Савыт* сүзенә фонетик анализ ясагыз.

3. *Өр-яңа* сүзенә морфологик анализ ясагыз.

4. Сүзләрнең антоним парларын языгыз:

*Өр-яңа* –

*Ак* –

*Яңгыр* –

5. *“Көзге яңгыр”* дигән темага 10 җөмлә языгыз.

**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре.**
**8 нче сыйныф**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Җөмләдәге тел арты (кече тел) ассимиляциясе чагылыш тапкан сүзләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Илләт кояшы, ерактагы зәңгәр урман эченә төшеп йоклар алдыннан, озын бер сузылып, төтен баганасын алтынга манды.* (Г.Бәширов)

а) 1;

ә) 2;

б) 3;

в) 4.

2. Тел-теш тартыкларының барысы да күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) [къ], [гъ], [х], [ң];

ә) [х], [н]; [къ], [гъ], [з], [д], [ц];

б) [д], [т], [з], [с], [л], [н], [ц];

в) [м], [н], [ң];

3. Җөмләдәге ТСТ калыбына туры килә торган иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Кояш югарырак үрләде, юкәне буеннан-буена яктыртты.* (М.Рәфыйков)

а) 2;

ә) 3;

б) 4;

в) 5.

4. Архаизм булган ***мәктүп*** сүзенең хәзерге көндә кулланыла торган варианты дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) мәктәп;

ә) хат;

б) мәкалә;

в) укучы.

5. Яңа сүзләрдән генә торган рәтне билгеләгез.

а) куцат, айбагар, шартлама, ызба;

ә) анализ, вакланма, интервал, формула;

б) дәрес, мәдрәсә, шәкер, мулла;

в) дресс-код, лайк, супервайзер, фастфуд

6. Җөмләдәге күчерелмә мәгънәле сүзнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Зур елгалар боз астына качтылар.* (Г.Ибраһимов)

а) образлы метафора;

ә) образлылыгын югалткан метафора;

б) индивидуаль-стилистик метафора;

в) метонимия.

7. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Кызы мендәрләр өстендәге чигелгән япмаларны, көзгегә эленгән чиккән сөлгене алып куя.* (Т.Миңнуллин)

а) япмаларны;

ә) өстендәге, япмаларны;

б) мендәрләр, өстендәге, япмаларны;

в) мендәрләр, өстендәге, япмаларны, көзгегә.

8. ***3,7; 9,2*** кебек саннарның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) микъдар;

ә) чама;

б) бүлем;

в) тәртип.

9. Җөмләдәге хәл фигыльләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр.* (Ә.Еники)

а) 2;

ә) 3;

б) 4;

в) 5.

10. Җөмләдге хәбәрнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Менә табигатьтә тагын алтын көз хакимлек итә.* (Д.Гыйсметдин)

а) тезмә исем хәбәр;

ә) кушма исем хәбәр;

б) тезмә фигыль хәбәр;

в) кушма фигыль хәбәр.

11. Җөмләдәге кереш сүзнең мәгънәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Гомумән, беркем дә эшсез утырмый.* (Ф.Әһлия)

а) ышану, раслау;

ә) фикергә бәйләнгән төрле тойгы;

б) фикер тәртибе;

в) фикер нәтиҗәсе, йомгагы.

12. Җөмлә эчендәге нокталар урынына тиешле тыныш билгесе куелган рәтне билгеләгез.

*“Яшь техниклар” журналының безгә очкыч ... самолёт ... ясарга өйрәткән бүлеге ошады.* (Д.Гайнетдинова)

а) – – ;

ә) ( ) ;

б) , , ;

в) : – .

## II. Башыгызны эшләтегез.

Һәр җөмләдә фразеологизм файдаланып, 15 җөмләдән торган “Кышкы табигать” дигән текст уйлап языгыз.

## III.Теоретик бирем.

Алынма сүзләр, аларның үзенчәлекләре турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз. Алынма сүзләргә үз мөнәсәбәтегезне белдерергә онытмагыз.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Үз илен яратмаган кеше берни дә яратмый.* (Мәкаль)

1. *Берни* сүзенә фонетик анализ ясагыз.

2. *Яратмаган* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез.

3. Барлык сүзләргә дә морфологик анализ ясагыз.

4. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә языгыз.

5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының йомгаклау этабы биремнәре.**

**8 нче сыйныф**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Хәзерге татар әдәби телендәге авазлар саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) 12;

ә) 24;

б) 39;

в) 40.

2. Җөмләдәге ачык иҗекләр саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Чишмә суы хәзер дә авылның иң кадерле сыйларыннан санала.* (Гомәр Бәширов)

а) 11;

ә) 12;

б) 13;

в) 14.

3. ***Эскерт*** сүзендәге аваз үзгәреше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) протеза;

ә) эпентеза;

б) эпитеза;

в) апокопия.

4. Җөмләдәге антонимнар дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Яшьлек артка, уңга-сулга карамый, алга чаба.* (Туфан Миңнуллин)

а) *артка – алга*;

ә) *уңга-сулга*;

б) *артка – алга, уңга-сулга*;

в) *артка – алга, уңга-сулга, карамый – чаба*.

5. Җөмләдәге алынма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Укытучы керде дә, аудиториягә карамый гына, портфелен өстәл янындагы утыргычка куйды, ачып, язулы кәгазьләрен алды, өстәлгә салды.* (Халисә Ширмән)

а) *аудиториягә*;

ә) *аудиториягә, портфелен*;

б) *аудиториягә, портфелен, кәгазьләрен*;

в) *аудиториягә, портфелен, өстәл, кәгазьләрен, өстәлгә*.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзгә дөрес аңлатма бирелгән рәтне билгеләгез.

*Үткән көннәрдәге* ***бәгъзе*** *авырлыклар бу көндә мал түгеп алачак җиңеллекләрне тудыра.* (Ризаэддин Фәхреддин)

а) *элеккеге*;

ә) *башка*;

б) *онытылмас*;

в) *үткән*.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән рәвешнең төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Тормышның теләсә нинди сынауларына әзер булырга тиеш кеше: югары менсә дә башы әйләнмәсен,* ***түбән*** *төшсә дә үзен югалтмасын.* (Шәүкәт Галиев)

а) саф;

ә) сәбәп-максат;

б) күләм-чама;

в) урын.

8. Җөмләдәге санның төркемчәсе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Хәзерге вакытта ташбакаларның 250 гә якын төре билгеле.* (Вакытлы матбугаттан)

а) микъдар;

ә) бүлем;

б) чама;

в) җыю.

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән күрсәтелгән берәмлекләрнең кайсы сүз төркеме икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Мияубикә иркәлеккә* ***бик*** *иркә,* ***ләкин*** *хәйләкәр: тәпиләре аның хәтфә* ***кебек, ә*** *тырнаклары,* ***ай-яй****, үткен.* (Константин Ушинский)

а) кисәкчә, теркәгеч, бәйлек, теркәгеч, ымлык;

ә) кисәкчә, теркәгеч, бәйлек, теркәгеч, модаль сүз;

б) рәвеш, теркәгеч, бәйлек, теркәгеч, ымлык;

в) кисәкчә, теркәгеч, бәйлек сүз, теркәгеч, ымлык.

10. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Тып-тыныч тормыш та кешедән **гел** батырлык сорый.* (Фәнис Яруллин)

а) вакыт хәле;

ә) күләм хәле;

б) тәмамлык;

в) аергыч.

11. Җөмләгә дөрес билгеләмә күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Акылсыз башка алтын бүрек файда бирмәс.* (Суфиян Поварисов)

а) инкяр, хикәя, җәенке, бер составлы, тулы, гади җөмлә;

ә) инкяр, боеру, җәенке, ике составлы, тулы, гади җөмлә;

б) раслау, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы, гади җөмлә;

в) инкяр, хикәя, җәенке, ике составлы, тулы, гади җөмлә.

12. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Өендә ялкаулык күрмәсә, бала ялкау булмый.* (Мөхәммәт Мирза)

а) гади җөмлә;

ә) тезмә кушма җөмлә;

б) күп тезмәле кушма җөмлә;

в) иярченле кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Текстны укыгыз, күп нокталар урынына төшеп калган сүзләрне языгыз. ***Шахмат*** сүзен ничек дип тәрҗемә итәргә була?

Шахмат турында беренче тапкыр VI гасырда Һиндстанда телгә алына. Ә шахмат сүзе каян алынган соң? Көнчыгышта хөкүмәт башлыгын – корольне – “шаһ” дип атыйлар, ә мат – “үлде” дигән сүз. Шахмат сүзен “**... ... ...** !” дип

тәрҗемә итәргә була. Уенның мәгънәсе нәкъ менә шунда да: ике армия – “ак” һәм “каралар” 64 шакмактан торган такта өстендә көрәш алып баралар. Армияләр составында 8 әр пешка, 2 шәр ат, 2 шәр фил, 2 шәр ладья, берәр ферзь (королева) һәм берәр король бар. *(Кем ул. Нәрсә ул.)*

Җавап: ..........................................................

### III.Теоретик бирем.

Фразеологизмнар турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз.

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

(1) Өебездә бердәнбер байлыгыбыз, һичшиксез, самовар иде. (2) Иртән дә, төш вакытында да, кичен дә, тишекләрдән пар чыгара-чыгара, гөрләп, бөтен өебезгә ямь биреп, табыныбызга килеп утыра торган иде.

(3) Хәзер өебездә электр, газ... (4) Шулай да без аны иң кадерле әйберебез итеп бик озак сакладык. (5) Ниһаять, тыгызлый башлады бу безне. (6) Гаилә зурая, әйбер күбәя, әлбәттә. (7) Яшьләр: “Өебез музейга охшый”, – дип көләләр... (8) Котылырга булдык без моңардан: комиссионныйга илтеп бирдем. (Мирсәй Әмирдән)

1. Сүз басымнарын билгеләп чыгыгыз.

2. ***Ниһаять*** сүзенә фонетик анализ ясагыз.

3. 2 нче җөмләдәге ясалма сүзләрне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләрен аерыгыз.

4. ***Бөтен, күбәя, әлбәттә, дип*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз.

5. Инверсия күренеше күзәтелгән җөмләләрнең номерларын языгыз.

6. Беренче җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз: җөмлә кисәкләрен һәм аларның төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә бирегез.

7. “***Самовар***” сезнең өчен нәрсә ул? Самоварның байлык булуын сез ничек аңлыйсыз? Өегезне музейга охшатып тора торган нинди әйберне сез комиссионкага илтеп бирер идегез? Шул хакта 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз.

**Татар мәктәбендә укучы балаларга**

**татар теленнән мәктәп олимпиадасы өчен биремнәр**

**11 нче сыйныф**

**I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.**

1. ***Маэмай*** сүзендәге тартык һәм сузык авазлар саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) 2 тартык, 4 сузык;

ә) 3 тартык, 3 сузык;

б) 2 тартык, 3 сузык;

в) 4 тартык, 2 сузык.

2. Фразеологизм кулланылган җөмләне билгеләгез.

а) Фәрит елга буенда балык тота иде. (Ә.Кари)

ә) Көзге көн бала кебек: әле елый, әле көлә. (Мәкаль)

б) Анын бәгырен корт кимерә иде. (Ф.Латыйфи)

в) Ат – чабышта, кеше эштә беленә. (Мәкаль)

3. Җөмләдәге ясалма сүзләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Ачык тәрәзәдән апаның кояш кебек түм-түгәрәк ипиләрне кызыл ашъяулыкка куеп бүлгәләве күренә.* (Ш.Маннапов)

а) бер;

ә) ике;

б) өч;

в) дүрт.

4. Җөмләләрдәге фигыльләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Тәвә кошлары очмый, ләкин бик яхшы йөгерәләр. Чүлдә аларны ат белән куып җитү дә җиңел түгел.* (Вакытлы матбугаттан)

а) очмый, йөгерәләр, җитү;

ә) очмый, йөгерәләр, куып;

б) очмый, йөгерәләр, куып, җитү, җиңел түгел;

в) очмый, йөгерәләр, куып, җитү.

5. Җөмләдәге кисәкчәләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Тып-тын, тик умывальник борыныннан чутылдап тамчы тамгалый да келт-келт сәгать йөри.* (Р.Төхфәтуллин)

а) тып-;

ә) тып-, да;

б) тик;

в) да.

6. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмлә кисәгенең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

Аларга бүген өйдә **грамматикадан** боерык фигыльле өч җөмлә язып килергә куштылар. (Г.Тавлин)

а) урын хәле;

ә) туры тәмамлык;

б) кыек тәмамлык;

в) рәвеш хәле.

7. Иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйли торган чара дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Сез күрдегезме җирдә дә бер йолдыз кабынганны?* (Ф.Бәйрәмова)

а) күтәрү интонациясе;

ә) *җирдә* бәйлек сүзе;

б) мөнәсәбәтле сүз;

в) -*ны* кушымчасы.

8. Җөмлә төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Язлар вәгъдә иткән җылылыкны,*

*Җәйләр үткәч, көзләр китерде.* (К.Булатова)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

## II. Теоретик бирем.

Хат стиле турында белгәннәрегезне языгыз.

## III. Гамәли һәм иҗади бирем.

*Уйламыйча, дустым бер сүз әйтте,*

*ул сүз йөрәгемә кадалды.*

*Үзе берни белми китеп барды,*

*ә сүз калды.* (И.Юзеев)

1. *Калды* сүзенә фонетик анализ ясагыз.
2. *Кадалды* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез.
3. *Уйламыйча* сүзенә морфологик анализ ясагыз.
4. Җөмлә кисәкләренең асларына сызыгыз, төрләрен билгеләгез.
5. Икенче җөмләнең схемасын сызыгыз, билгеләмә бирегез.
6. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре.**

**11 нче сыйныф**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүздәге аваз үзгәреше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Көзге салкын яңгыр, кемгәдер ачулангандай, тәрәзәгә бәрә, әйтерсең лә тышта калган юлчы җылы* ***фатирга*** *кертүеңне үтенә.* (И.Нәбиуллин)

а) протеза;

ә) эпентеза;

б) эпитеза;

в) апокопия.

2. Җөмләдәге ябык иҗекләрнең саны дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Ап-ак ашъяулык ябылган буш өстәлләрне читләтеп, Бәхтияров студент әйткән сулъяк түргә узды.* (М.Насыйбуллин)

а) 18;

ә) 20;

б) 21;

в) 23.

3. Җөмләдәге алынма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Хәер, сакчылар гына түгел, очкыч тәгәрмәчләре тәгәрәүдән туктап, бер сәгать үтәр-үтмәс, полк штабына әйләнгән землянкаларда да йокламыйлар әле.* (Ш.Рәкыйпов)

а) полк, штабы, землянкаларда;

ә) хәер, сәгать, полк, штабы, землянкаларда;

б) хәер, сәгать;

в) хәер, очкыч, сәгать, полк, штабы, землянкаларда.

4. Шигырьдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзләрнең атамасы дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Шунда беренче тапкыр*

*Очраттым мин* ***балтырган***.

*Белмәгәндә, мине көтеп*

*Көпшәсендә* ***бал торган.*** (Ш.Галиев)

а) саф лексик;

ә) омофоннар;

б) омографлар;

в) омоформалар.

5. Җөмләдәге ясалма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Яңгыр шыбырдаганы җанга тия, эре тамчылар калай тәрәзә төбенә шулкадәр каты килеп төшә ки, ул гел башка сугып торган кебек шакылдый: тып та тып, тып та тып.* (И.Нәбиуллин)

а) шыбырдаганы, тамчылар, шулкадәр, шакылдый;

ә) тып та тып, тып та тып;

б) шыбырдаганы, тамчылар, шакылдый;

в) шулкадәр.

6. Җөмләдәге аваз ияртеменең төзелеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Ул барында да тузанга болай рәхәтләнеп,* ***лап-лоп*** *итеп баса алмыйсың, өстәл янында аягыңны селкетеп тә утыра алмыйсың.* (Р.Фәизов)

а) ялгызак;

ә) парлы;

б) кабатланып килгән;

в) өч компонентлы.

7. Җөмләдәге кисәкчәләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Тик дөньядагы иң ачык төс итеп һәркем үз әнисенең күзләре төсен күрәдер.* (Р.Мингалим)

а) тик;

ә) тик, иң;

б) иң, һәр, -дер;

в) иң, -дер.

8. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзгә морфологик анализ дөрес ясалган рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Үлән өстеннән мүкәләп* ***барсаң****, күзне камаштырып, җир җиләге килеп чыга.* (Г.Ахунов)

а) киләчәк заман хикәя фигыль, затланышлы, төп юнәлештә, барлыкта, II зат берлек санда, тамыр;

ә) шарт фигыль, затланышлы, кайтым юнәлешендә, барлыкта, II зат берлек санда, тамыр сүз;

б) шарт фигыль, затланышлы, төп юнәлештә, барлыкта, II зат берлек санда, тамыр сүз;

в) шарт фигыль, затланышсыз, төп юнәлештә, барлыкта, II зат берлек санда, тамыр сүз.

9. Җөмләдәге ияләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Бу якты җиребез, ай-кояшлы, йолдызлы күк, серле галәм – һәммәсе дә әниләр йөрәге белән җылытылып, яктыртылып калган.* (Ф.Садриев)

а) җиребез, күк, галәм, һәммәсе;

ә) җиребез, ай-кояшлы, күк, галәм;

б) җиребез, күк, галәм, әниләр;

в) җиребез, күк, галәм.

10. Л.Ихсанова иҗатыннан тупланган мисаллар арасыннан инверсия (кире сүз тәртибе) чагылыш тапкан җөмләне билгеләгез. (2 балл)

а) Чишмә янында да ялгыз шомырт агачы үсә.

ә) Ул инде бик карт агач.

б) Берсен дә онытмаган, бер ишен дә калдырмаган!

в) Күр инде тау битендәге ул агачларны!

11. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Өем минем яктырсын дип, ут элдердем шәмнәргә.* (Л.Лерон)

а) аналитик иярчен максат җөмлә;

ә) синтетик иярчен максат җөмлә;

б) аналитик иярчен сәбәп җөмлә;

в) синтетик иярчен сәбәп җөмлә.

12. Кушма җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. (2 балл)

*Аның сүзләре шундый ягымлы, шундый йомшак, җылы иде ки, врач апа сөйләшкән саен, баш авыртуы кими бара, баш эчендә янган ялкын сүрелә төшә, кулларга, аякларга җылы йөгерә.* (Р.Вәлиев)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

ә) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) катнаш кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Сорауларга җавап языгыз.

Кайсы бәйлек сүз хикәя фигыль дә булып санала?

Кайсы бәйлек сүз боерык фигыль дә булып килә?

Кайсы бәйлек рәвеш тә булып санала?

Кайсы бәйлек сүз тартым белән төрләнгән кеше әгъзасына урын-вакыт килеше кушымчасы ялганып ясалган?

Кайсы бәйлек сүз кеше әгъзасына юнәлеш килеше кушымчасы ялганып ясалган?

## III.Теоретик бирем.

Сан сүз төркеме турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә дәлилләгез. Саннарның дөрес язылышы белән бәйле кагыйдәләрне искәртеп китәргә онытмагыз.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

*Әни сөртә иртән көзгеләрне,*
*Уйчанланып кала күзләре:*
*Еллар инде узган,*
*Хәтер сандыгыннан*
*Йөгереп үтә яшьлек эзләре.* (Р.Акъегет)

1. *Йөгереп* сүзенә фонетик анализ ясагыз.

2. *Уйчанланып* сүзенең мәгънәле кисәкләрен билгеләгез.

3. *Иртән, инде, узган, яшьлек* сүзләренә морфологик анализ ясагыз.

4. Җөмләнең баш кисәкләрен һәм компонент чикләрен билгеләгез, схемасын сызыгыз, җөмләгә билгеләмә бирегез. Тыныш билгеләренең куелышын кагыйдәләргә таянып аңлатыгыз.

5. Әлеге тема белән бәйле фикерләрегезне 12-15 җөмләдән торган бәйләнешле текст итеп языгыз.

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының йомгаклау этабы биремнәре.**

**11 нче сыйныф**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Сүзләрдәге аваз охшашлану күренеше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Унбиш, унбер, ун пот, туксан биш.*

а) ирен ассимиляциясе;

ә) борын ассимиляциясе;

б) яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта охшашлану;

в) тел арты ассимиляциясе.

2. ***Керән*** сүзендәге аваз үзгәреше дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

а) протеза;

ә) эпентеза;

б) эпитеза;

в) апокопия.

3. Шигырьдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзгә дөрес аңлатма бирелгән рәтне билгеләгез.

***Энҗе*** *карлар сибеп, ак кыш килде,*

*Бөтерелеп бии шаян җил.*

*Ак күбәләк патшалыгы мәллә,*

*Тоташ актан бүген бөтен җир.* (Дания Гайнетдинова)

а) образлылыгын югалткан метафора;

ә) образлы метафора;

б) индивидуаль-стилистик метафора;

в) метонимия.

4. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзгә дөрес аңлатма бирелгән рәтне билгеләгез.

*Тәнеңнең гомерлек табибе бул, телеңнең гомерлек* ***талибе*** *бул.* (Зиннур Мансуров)

а) шәкерте;

ә) юлдашы;

б) дошманы;

в) укытучысы.

5. Өзекнең кайсы диалект вәкиле сөйләме икәнлеге дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

[*суп эшлиләр / ыфтаруйга ит / пылау / йәшел суган / йымырка белән пирашки пешерәләр / пирук зур / камырны / майга / йымыркага басалар // алма пируклары пешерәләр //*] ("Татар халык сөйләшләре" китабыннан)

а) Урта диалект;

ә) Көнбатыш диалект (мишәр диалекты);

б) Көнчыгыш диалект (Көнбатыш Себер татарлары);

в) Казан диалекты.

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең мәгънәле кисәкләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

***Бүгенгедәй*** *хәтеремдә: Мишә буенда атлар утлавын күзәтәбез.* (Дания Гайнетдинова)

а) *бу* – тамыр, *көн* – тамыр, -*ге* – сыйфат ясагыч кушымча, -*дәй* – рәвеш ясагыч кушымча, нигезе – *бүгенгедәй*, ясалма нигез;

ә) *бүген* – тамыр, -*ге* – сыйфат ясагыч кушымча, -*дәй* – рәвеш ясагыч кушымча, нигезе – *бүгенгедәй*, ясалма нигез;

б) *бу* – тамыр, *көн* – тамыр, -*ге* – сыйфат ясагыч кушымча, -*дә* – урын-вакыт килеше кушымчасы, -*й* – рәвеш ясагыч кушымча, нигезе – *бүгенгедәй*, ясалма нигез;

в) *бу* – тамыр, *көн* – тамыр, -*ге* – сыйфат ясагыч кушымча, -*дәй* – рәвеш ясагыч кушымча, нигезе – *бүгенге*, ясалма нигез.

7. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүз төркеменә дөрес морфологик-синтаксик анализ ясалган рәтне билгеләгез.

***Эчәр*** *су да чамасы кадәр генә булса яхшы.* (Котб)

а) билгесез киләчәк заман хикәя фигыль, III зат берлек санда, барлыкта, тамыр, җөмләдә – аергыч;

ә) киләчәк заман сыйфат фигыль, затланышсыз, барлыкта, тамыр, җөмләдә – аергыч;

б) билгеле киләчәк заман хикәя фигыль, III зат берлек санда, барлыкта, тамыр, җөмләдә – аергыч;

в) киләчәк заман сыйфат фигыль, затланышсыз, барлыкта, ясалма, җөмләдә – аергыч.

8. Җөмләдәге сыйфатлар һәм аларның дәрәҗәләре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Басу җете яшел, уҗым чип-чиста, юлдан килгән тузанлы кием белән керергә уңайсыз...* (Шәүкәт Галиев)

а) *яшел* – гади дәрәҗәдә, *чип-чиста* – артыклык дәрәҗәсендә;

ә) *яшел*, *чип-чиста*, *тузанлы*, *уңайсыз* – гади дәрәҗәдә;

б) *җете яшел*, *чип-чиста*, *тузанлы*, *уңайсыз* – артыклык дәрәҗәсендә;

в) *җете яшел, чип-чиста* – артыклык дәрәҗәсендә, *тузанлы, уңайсыз* – гади дәрәҗәдә.

9. Җөмләнең иясе дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Үз моңын оныткан бүтәннәр моңын ишетми башлый.* (Туфан Миңнуллин)

а) *үз*;

ә) *моңын*;

б) *оныткан*;

в) *бүтәннәр*.

10. Җөмләгә дөрес билгеләмә күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Бер үк суга ике мәртәбә кереп булмаса да, бер елганы ике мәртәбә кичеп була.* (Галимҗан Гыйльманов)

а) хикәя, җәенке, бер составлы, тулы, гади җөмлә;

ә) хикәя, җәенке, ике составлы, ким, гади җөмлә;

б) хикәя, җәенке, бер составлы, ким, гади җөмлә;

в) иярченле кушма җөмлә.

11. Иярчен җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Әгәр дә матурлык бөтен кешедә дә булса, ул матурлык булудан туктар иде.* (Рабит Батулла)

а) аналитик иярчен ия җөмлә;

ә) синтетик иярчен кире җөмлә;

б) аналитик иярчен шарт җөмлә;

в) синтетик иярчен шарт җөмлә.

12. Калын хәрефләр белән бирелгән җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез.

*Сүзеңне үлчәп әйт: әйтелгән сүз – атылган ук.* ***Ук бәгырьгә кадалгач, үкенүләр соң була, җәрәхәт мәңгегә кала.*** (Рабит Батулла)

а) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

ә) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

б) бер-бер артлы иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;

в) катнаш кушма җөмлә.

## II. Башыгызны эшләтегез.

Ябык иҗекле сүзләрдән генә торган 10 җөмлә ярдәмендә “Кыш көне” дигән текст языгыз.

## III.Теоретик бирем.

Җөмләнең баш кисәге – ия турында белгәннәрегезне языгыз. Фикерләрегезне мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз.

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

(1) Нәкыя, кунакларны озаткач, өйне тәртипкә китерергә тотынды. (2) Өй эче тәртипсез түгел: идәннәр юылган, тәрәзәләр сөртелгән. (3) Кызы, шәһәрдән кайткач, өйне үзенчә җыештыра башлый. (4) Чигелгән тәрәзә пәрдәләрен сарылы-кызыллы озын пәрдәләр белән алмаштыра. (5) Өйгә урам яктысы да керми. (6) Мендәрләр өстендәге чигелгән япмаларны, көзгегә эленгән чиккән сөлгене алып куя. (7) Нәкыя дәшми. (8) Үзе генә калгач, өйне үзенчә тәртипкә китерә. (9) Чиккән сөлге үз урынына эленде. (10) Мендәрләр элеккеге япмалар белән капланды. (Туфан Миңнуллиннан)

1. Сүз басымнарын билгеләп чыгыгыз.

2. Яңгыраулыкта һәм саңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз.

3. ***Элengән*** сүзенә фонетик анализ ясагыз.

4. Ясалма сүзләрне күчереп языгыз.

5. ***Озаткач, юылган, сарылы-кызыллы, чигелгән, элеккеге*** сүзләренә морфологик-синтаксик анализ ясагыз.

6. 2 нче һәм 4 нче җөмләләргә тулы синтаксик анализ ясагыз: җөмлә кисәкләрен һәм аларның төрләрен билгеләгез, җөмләгә билгеләмә бирегез, кушма җөмлә булса, схемасын сызыгыз.

7. XX гасыр башындагы татар өен XIX гасырныкы белән чыгыштырып, 10-12 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. Сез карт әби-бабагызның өеннән нинди җиһазларны үзегезгә алыр идегез?

**Әдәбият исемлеге**


1. Галиуллина Г.Р., Шәкүрова М.М. Татар телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләре өчен ана теленнән программа (5—9 нчы сыйныфлар). http://mon.tatarstan.ru/rus/file / pub / pub_263448. docx.

2. Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. Татар теленнән презентацияләр. 664 слайд. — Казан: «Мәгариф—Вакыт» нәшр., 2016. (диск)

3. Татар теле (кагыйдәләр, методик киҗәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). Абитуриентлар, укытучылар, студентлар өчен. / Мирзаһитов Р.Х., Сәгъдиева Р.К., Хөснетдинов Д.Х. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2017. – 191 б.

4. Хөснетдинов Д.Х., Сәгъдиева Р.К. Татар теленнән олимпиадага әзерлибез (методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). 4–7 нче сыйныфлар. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2016. – 168 б.

5. Хөснетдинов Д.Х., Сәгъдиева Р.К. Татар теленнән олимпиадага әзерлибез (методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). 8–9 нчы сыйныфлар. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2016. – 192 б.

6. Хөснетдинов Д.Х., Сәгъдиева Р.К. Татар теленнән олимпиадага әзерлибез (методик киңәшләр, анализ үрнәкләре, биремнәр). 10–11 нче сыйныфлар. – Казан: "Мәгариф-Вакыт" нәшр., 2016. – 192 б.